ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.09.2025 Олы Кайбыч ав. № 440

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Кайбыч муниципаль районы территориясендә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2025 елның 16 гыйнварындагы 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Кайбыч муниципаль районы территориясендә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2025 елның 16 гыйнварындагы 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаның 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Комиссия 15 кешедән тора, шул исәптән рәис, рәис урынбасары һәм комиссиянең 13 әгъзасы. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының 2/3 катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.»;

1.2. 3 нче кушымтада:

- составка комиссия әгъзасы итеп – Татарстан Республикасы хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кайбыч муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы Тимершина С.Б.ны кертергә (килешү буенча);

- комисия составыннан Баһавеева Н.А.ны төшереп калдырырга.

1.3. 6 нчы кушымтаның 6 пунктының 6.1. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Балаларны савыктыру оешмаларында ял итү һәм сәламәтләндерү өчен ата-аналар түләвенең күләме Татарстан Республикасында балаларны оештыруга һәм сәламәтләндерүгә финанс чыгымнары нормативының 15 проценты күләмендә билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров